# Иҗади сәхифә

Сәхифәне оештыручылар: 3 нче мәктәпнең татар теле һәм әдәбияты укытучылары методик берләшмәсе

**апрель, 2021нче ел**

## Иң татлы тел — туган тел,
## Анаң сөйләп торган тел.




2021 нче ел Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы булачак. Бу хакта Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов тәкъдим итте.

Мәктәбебездә дә бу зур вакыйганы ачып җибәрү тантанасы булып үтте. Иртәдә мәктәп шау-гөр килде. Фойеда килгән укытучыларны һәм укучыларны төрле телләрдә сәламләп каршы алдылар. Телләр турында әйтелгән матур сүзләр дә төрле телләрдә яңгырады. Укучыларга телләр турында кызыклы мәгълүматлар җиткерелде. Төрле милләт көйләрен башкардылар, ә тәнәфестә рус һәм татар халык уеннарын уйнадылар, төрле милли җырларны тыңладылар. Бәйрәм бик кызыклы булды!








**И туган тел, и матур тел,**
**әткәм-әнкәмнең теле!**
**Дөньяда күп нәрсә белдем**
**син туган тел аркылы.**

### Габдулла Тукайга багышлап....



Бөек татар шагыйребез Габдулла Тукайны барыбыз да хөрмәт итә, чөнки ул халкыбызның улы. Аның шигырь-әкиятләрен укып үсәбез. Тукай геройлары дөрес юлдан барырга чакыралар, яхшы эшләр эшләргә өндиләр. Бу шигырьләр гаҗәеп бер тәэсир калдыралар. Шуңа да аларны укыйбыз, укыйбыз...

«Гомер буе юлдаш булып,
Ир-хатынга иптәш булып, чордаш булып,
Җиребездән атлап, Тукай барасың син,
Йөрәкләргә тугры юллар ярасың син...»

Сәлисә Гәрәева

Тукайга.

Шагыйрьләрнең шагыйре син,
Остазларның остазы.
Олуг Тукай, бөек Тукай-
Халкымның бер баласы.
Үткәнне һәм Киләчәкне
Шигырь аша сөйләгән.
Халкымның бөтен зар-моңын
Көйгә салып көйләгән.
Зурлыйлар аны халыклар
Баш ияләр алдында.
Тукай теле- татар теле
Сөйли халкым хакында.

Әхмәтшина Лариса Михаил кызы,
туган тел һәм әдәбияты укытучысы



Ел саен мәктәбебездә Габдулла Тукайга багышлап төрле кызыклы чаралар һәм бәйгеләр үткәрелә. Аларда күп укучылар теләп катнаша. Кайберәүләр – шигырь бәйгеләрендә, кайберләре – рәсем бәйгесендә, укучылар арасында спектакль күрсәтүчеләр дә бар. Тукайны искә алу атнасында мәктәп гөрләп тора. Җыр – бию, шигырьләр, сәхнәләштерү – барысы да Тукаебызның бәйрәмен искә төшертә. Бик күңелле үтә бу язгы бәйрәм!




Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елынының ачылу тантанасы районыбызның гимназиясендә дә үтте. Бу чарада туган тел һәм әдәбияты укытучылары белән бергә безнең укучылар да актив катнаштылар.

Чарада районда яшәгән төрле милләт балалары катнаштылар: биеделәр, җырладылар, шигырь сөйләделәр. Безнең мәктәп укучысы  Сәидов Нариман да сәхнәдә чыгыш ясады. Ул үзенең туган таҗик телендә шигырь сөйләде. Нариманның туган телен камил белүе, шул ук вакытта татар телен дә теләп укуы, рус телендә дә сөйләшә алуы, инглиз телен дә өйрәнүе сокландыра.

Бәйрәм искиткеч матур узды һәм укучыларның күңелләрендә калды.

***

Татар әдәби әсәрләрен сәнгатьле укучыларның ”TATAR СҮЗЕ” республикакүләм бәйгесен оештыручысы – Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе иде. Бу бәйгедә безнең мәктәп укучылары да катнашты. 4 нче Г сыйныфы укучысы Самерханов Гадел рәхмәт хаты белән бүләкләнде. Ул Губдулла Тукайга багышланган шигырьне башкарды.

Сәхнәдә “Сәләт” театр түгәрәге.

“Сәләт” театр түгәрәге үз эшен дәвам итә. Бу юлы түгәрәк җитәкчеләре иң катлаулы эшләрнең берсе- Муса Җәлил шигыре өстендә эшләргә тәкъдим иттеләр. Укучылар “Вәхшәт” шигырен сәхнәләштерделәр. Сугыш еллары геройларын күрсәтү бик авыр булды, чөнки безнең укучылар сугыш афәтен телевизордан күрәләр, ә сәхнәдә күрсәтү икеләтә катлаулырак. Шуңа да карамастан бу эшне җиренә җиткерделәр, видеоязмага төшерделәр. Бик кызганыч сәхнә әсәре уңышлы тәмамланды.



Курчак театры.

Татар теле һәм әдәбияты укытучылары Гарфеева А.М. һәм Шәйхетденова Ә.С. җитәкчелегендә сәхнәдә курчак театрлары куелды. Спектакльләрдә беренче, дүртенче сыйныф укучылары катнаштылар. Алар А.Алишның “Сертотмас үрдәк” әкиятен тамашачыга җиткерделәр. Башлангыч сыйныф укучылары курчак-геройлар белән уйнарга өйрәнделәр. Бу алар өчен аеруча кызыклы булды. Спектакль тамашачыларга бик ошады.



**Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елына багышлап...**

Мәктәптә мин 3 тел өйрәнәм: рус теле, татар теле һәм инглиз теле. Минемчә, телләр өйрәнү бик мөһим.Телне белсәң, син күп кызыклы урыннарда була аласың һәм синең алдыңда күп мөмкинлекләр ачыла. Телләрнең теләгәнен өйрәнергә кирәк, синең өчен кызыклы булган телне укырга кирәк. Минем мәктәптә дә телне сайлау иреге бар. Рус теле бик кирәкле тел, чөнки сүзләрнең килеп чыгышын, аларның үзгәрүен өйрәнү мөһим. Татар теле дә кирәк, чөнки без Татарстан республикасында яшибез.

Хорошева Яна, 7 нче сыйныф укучысы

***

Телләрну өйрәнү кирәкме? Моңа мин бик уңай карыйм. Беренчедән, телләрне өйрәнү хәтерне яхшырта һәм кешенең сүзлек байлыгы арта. Икенчедән, кеше күп тел белсә, ул дөнья буйлап сәяхәт итә ала. Өченчедән, без телләрне өйрәнсәк, китаплар укый алабыз, фильмнар карау мөмкинлеге ачыла, төрле милләт кешеләре белән аралашып була.

Хамзина Варвара, 7 нче сыйныф укучысы

***

Минем туган телем- татар теле. Ул миңа әти-әни , дуслар, туганнар белән аралашу өчен кирәк. Татарт телен белсәң, күп көнчыгыш илләренең телләрен аңлап була.Рус теле бик катлаулы тел булса да, аны өйрәнергә кирәк, чөнки ул бөтен җирдә кирәк.Мин әле инглиз телен дә укыйм. Инглиз телен яхшы белгән кеше төрле илләрдә сәяхәт итеп, төрле кешеләр белән аралаша ала, чөнки инглиз телендә дөньядагы күпчелек кеше сөйләшә.Тел аша дөньяны өйрәнү мөмкинлеге туа, сөйләм теле үсә.

Иванова Лилия, 7нче сыйныф укучысы



***Татар халык әкияте “Батыр әтәч”***



***Китапханәдә экскурсиядә***



***Туган телләр елына стенд***



**Телебез турында.**

“Без - татарлар, телебез - татар теле, мөстәкыйль һәм төзек кагыйдәле камил тел ул”.

К.Насыйри

“Тел – халыкның кыйммәтле күңел хәзинәсе”.

Гомәр Бәширов

“Тел ул буыннан-буынга ана сөте белән күчә килгән һәм күчәчәк мөкатдәс бер мирас. Тел, ниһаять, туган ил, туган җир ул.”

Х. Сәрьян

“Халыкның теле - аның рухи тормышының иң яхшы, беркайчан да шиңми, мәңге яшәреп тора торган иң матур чәчәге. Телдә халык һәм аның Ватаны җанлы рәвештә гәүдәләнә, телдә халыкның бөтен рухи тормышының тарихы чагыла”.

К.Ушинский


Тел дигән дәрья бар,
Дәрья төбендә мәрҗән бар:
Белгәннәр чумып алыр,
Белмәгән коры калыр.

Дәрдемәнд

Саклап телне, сакла безне,
Татар теле мөгаллиме!
Рәхмәт сиңа!

Э. Шәрифуллина

Җыр булырлык сүзләр биргән,
Туган телем, рәхмәт сиңа!



**Пилецкая Дарья, 2нче сыйныф**

Минем әниемнең исеме - Юлия. Аның ике кызы бар: мин һәм минем апам Катя. Минем әнием бик акыллы һәм матур. Ул безгә бик тәмле ашлар пешерә. Без әниебезне бик нык яратабыз.



**Валеев Ренат, 4нче сыйныф**

**Әниемне яратам.**
**Валеев Айнур, 2нче сыйныф**

Әниемне яратам мин,
Аңа һәр көн елмаям
Әниемне яратам мин
Ансыз бер көн торалмам.
Көн дә җылы караш белән
Мәктәптән көтеп ала.



**Әни, рәхмәт!**
**Имамов Альмир, 9 нчы сыйныф**

Әнием, бик зур рәхмәт сиңа,
Күпме эшләр башкардың син, ничә еллар!
Мин кечкенә булганда да, зур үскәч тә,
Мине карап, мине көйләп үтеп киткән.

Хезмәтеңне онытмадым, онытмамын!
Сиңа ярдәм кирәк булса – булышырмын.
Ни телисең – синең өчен мин эшләрмен,
Рәхмәт сиңа, әнием минем, бик зур рәхмәт!

**Әниемә теләкләр.**

**Салдаев Данил, 2нче сыйныф**

Әниемнең җылы, назлы кулы
Безне саклап, назлап үстерә.
Күңелдәге изге теләкләре
Көтмәгәндә бәхет китерә.
Әниемнең гомере озын булсын,
Көләч, һәрчак шат булсын.
Безнең үскәнне күреп соклансын.

